| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 27.10.2023 | г. Казань | № 339-4/э-2023 |

«Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-8/э карары белән билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2023 елның 27 октябрендәге 45-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына 2024 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020-2024

елларга индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-8/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 25.11.2020 №273-9/э-2020, 24.11.2021 №345-13/э-2021, 28.10.2022 №269-6/э-2022 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Д.А. Сапожников

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 11.12.2019
№3-8/э карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.10.2023 № 339-4/э-2023
карары редакциясендә)

2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 664 335,08 | 139,86 | 1,68498 | 664 335,08 | 139,86 | 1,68498 |
| | | 2021 | 736 452,26 | 163,65 | 1,87863 | 736 452,26 | 163,65 | 1,87863 |
| | | 2022 | 728 770,21 | 163,53 | 1,85834 | 728 770,21 | 163,53 | 1,85834 |
| | | 2023 | 730 006,61 | 182,19 | 1,87988 | 730 006,61 | 182,19 | 1,87988 |
| | | 2024 | 840 417,97 | 176,81 | 2,13127 | 840 417,97 | 176,81 | 2,13127 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 №3-8/э карарына
3 нче кушымта (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
27.10.2023 № 339-4/э-2023
карары редакциясендә)

2020-2024 елларга (югалтуларны исәпкә алмыйча) «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалының кирәкле тулай табышы

| Т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Оборонэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Нократ» филиалы | 2020 | 24 792,99 |
| | | 2021 | 25 982,04 |
| | | 2022 | 22 856,85 |
| | | 2023 | 26 288,49 |
| | | 2024 | 36 739,10 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге